ГЛАВА НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Заводская, д.55, с. Нижний Услон, 422574

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Завод ур., 55 нче йорт, Түбән Ослан авылы, 422574

Тел.: (84379) 3-05-44, факс: (84379) 3-05-44.

18.11.2025г, № 2

На №______________ от________________

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге Түбән Ослан авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Түбән Ослан җирлеге Уставының 24 статьясы, 22.11.2013 ел № 909 (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, «Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 14 474 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?- Ленин урамы буенча торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән сорау буенча 2025 елның 18 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 19 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 19 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 19 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан торак пункты территориясендәге гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 14 474 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- Ленин урамы буенча торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә:

3. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан торак пункты территориясендәге гражданнар җыены нәтиҗәләрен Түбән Ослан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.В.Архиреев